

Хатын-кызларны зурлап бәйрәм алдыннан Мордовиянен һәрбер почмагында торле-торле чаралар vтте. Шуларнын кайберләре турында язу артык булмас дип уйлыйм.
Халыкара хатын - кызлар ко-ненә һәм Россия халыклары бердәмлеге елына багышланган «Милләт гvзәле-2026» конкурсы Черемиш авылында vткән. Чараны Ләмберә районы Черемиш топ мәктәбе тәрбия буенча директор кинәшчесе Лариса Хайдар кызы Чуракова, авыл мәдәният йорты Саида Исмаил кызы Карабанова һәм авыл китапханәсе Лариса Бари кызы Солдатова белән берлектә оештырганнар.
Әлеге конкурста «Татарочки», «Мордовочки» һәм «Русские искорки» командалары катнашкан. Командалар жюри хокеменә vзләренен визит карточкаларын тәкъдим иткәннәр.      Ярышта гvзәлләрнен гvзәле булган кызлар vзләре, рус, татар, мордва халкынын гореф-гадәтләре, милли ризыклары һәм ижади номерлары турында сойләгәннәр, кvрсәткәннәр. Кызлар шулай ук халык мәкальләрен, ашамлыкларын һәм биюләрен белvдә дә коч сынашканнар.
Һәр команда vз номинациясендә ин яхшысы булды, ә тамашачылар симпатиясе призы «Татарочка» командасында. Жинvче - 8 класс укучысы Аиша Юськеева. Ул безгә укуда да, чараларда да беренче һәм призлы урыннар яулаучы дип билгеле. Мәсәлән, 6 класстан башлап һәр ел татар теле һәм татар әдәбияты олимпиадаларында катнашып унышларга ирешә, республика кvләмендә татар теле буенча оештырылган шигырьләр конкурсларында жинvче һәм әлеге бәйрәмдә дә беренче булды.
Әлеге ярыш барлык хатын-  кызларнын мактауга лаеклы иттерелеп тәрбияләнvләре, әби-бабайларыннан килгән мирасны саклаучылары дип белдерде. Алар барысы да унган-булганнар.
Әлеге чара Черемиш халкы очен чын бәйрәм булды: сок-ландылар, шатландылар,

конкурсантлар очен жан аттылар. Бәйрәм конкурста катнашучылар әзерләгән милли ризыкларны татып карау белән тәмам-ланды.

**Наилә НАСЫРОВА**